**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «7» июленнән № 24-183

2021 елда мәгарифне үстерү стратегиясе кысаларында 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәгарифне үстерү комплексны программасын тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы А.И.Бутинаның «2021 елда мәгарифне үстерү стратегиясе кысаларында 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәгарифне үстерү комплексны программасын тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар» турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «2021 елда мәгарифне үстерү стратегиясе кысаларында 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәгарифне үстерү комплексны программасын тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар» турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә тәкъдим итәргә:

- белем бирү оешмаларын кадрлар белән тәэмин итү эшен дәвам итәргә;
- балаларның психологик халәтен һәм сәламәтлекне саклау эшен тикшереп торуны көчәйтергә;
- белем бирү сыйфатын бәяләүнең муниципаль системасын үстерүне тәэмин итәргә, укучыларның белемнәрен объектив бәяләүне тәэмин итүгә һәм ирешкән уңышлардан нәтиҗәле файдалануга аерым игътибар бирергә;
- дәүләт йомгаклау аттестациясенә сыйфатлы әзерлекне тәэмин итәргә;
- һәр мәктәпнең белем бирү сыйфаты мониторингын алып барырга, ай саен анализларга һәм белем бирүнең сыйфатын күтәрү өчен чаралар күрергә;

- гомуми белем бирүнең сыйфатын күтәрү, Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлек сыйфаты буенча чараларны оештыру өчен шартлар тудыру эшен дәвам итәргә, барлык фәннәр буенча да түбән чикне узучылар санын 100% ка һәм чыгарылыш сыйныф укучылары тарафыннан 100% аттестат алуга ирешергә;

- «Дәрестән соңгы мәктәп» проекты кысаларында өстәмә белем бирү системасын үстерү кысаларында фәнни-техник иҗатны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны нәтиҗәле куллануны тәэмин итәргә.

- мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һәм инвалид балаларны өстәмә гомуми белем программалары белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын кабул итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы

В. М. Козлов